# ДЖЕННИ ДЖОАНССОН – БРАСС БЕЛӘН 50 МЕТРГА ЙӨЗҮДӘ ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНКАСЫ

09.08.2015, 17:58

СПОРТ

**Бу минутларда су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионатының соңгы ярыш көненең икенче финал йөзеше тәмамланды. Пьедесталдагы урыннар өчен дөньяның иң җитез 8 йөзүче кызы ярышты.**

Брасс белән 50 метрга йөзүдә алтын медальне Швеция кызы Дженни Джоансcон алды, бу араны ул 30.05 секундта йөзеп узды. Аның артыннан финишка, 30.11 секундлы нәтиҗә белән, Ямайка спортчысы Алиа Аткинсон килеп җитте. Призлы өлекне Россия йөзүче кызы Юлия Ефимова япты, аның күрсәткече - 30.13 секунд.

ДЧ-2015. Йөзү.

Хатын-кызлар. Брасс, 50 м.

1. Дженни Джоансcон (Швеция) - 30.05

2. Алиа Аткинсон (Ямайка) - 30.11

3. Юлия Ефимова (Россия) - 30.13

9 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА